# ЛАСЛО ЧЕХ – БАТТЕРФЛЯЙ БЕЛӘН 200 МЕТР ДИСТАНЦИЯГӘ ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

05.08.2015, 18:02

СПОРТ

Әлеге минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында икенче финал йөзеше тәгәлләнде. Баттерфляй белән 200 метр дистанциягә йөзү буенча дөньяның иң әйбәт 8 йөзүчесе ярышты.

Дөнья чемпионы булып венгр Ласло Чех калды – финалга ул 1:53.48 күрсәткече белән беренче булып килде. Аның җиңүе яңалык булмады – Ласло Чех биш тапкыр Олимпия чемпионы, күп тапкыр Дөнья чемпионатлары призеры. Аның артыннан финишка Көньяк Африка Республикасы спортчысы Чад ле Кло килде, аның күрсәткече – 1:53.68. Бронзаны Польша йөзүчесе Ян Свитковски яулады – ул күрсәткән вакыт – 1:54.10.

ДЧ-2015. Йөзү

Ир-атлар. Баттерфляй, 200 м.

1. Ласло Чех (Венгрия) - 1:53.48

2. Чад ле Кло (Көньяк Африка Республикасы) - 1:53.68

3. Ян Свитковски (Польша) - 1:54.10

5 август. Казан. "Казан Арена"

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА